Каралды:
Әтнә районы «Мәгариф бүлеге»
муниципаль казна учреждениесы җитәкчесе
________________ Р.Р.Фатыхов

Раслыйм:
Әтнә районы «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе директоры
________________ М.Н.Гарипова

# «Шигъри дулкыннар» шигырь укучылар бәйгесе нигезләмәсе
## (Россиядә Халыклар бердәмлеге һәм Татарстан Республикасында хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елына багышлана)

**Максат:** милли мәдәниятләрнең байлыгын, халыклар дуслыгын һәм үзара аңлашуын шигъри юллар аша чагылдыру; хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге кебек мөһим кыйммәтләрне яшь буынга җиткерү, аларны патриотик рухта тәрбияләү.
**Бурычлар:**
- балаларны татар һәм башка милләт шагыйрьләренең иҗатлары белән таныштыру;
- камил, дөрес итеп сәнгатьле сөйләм, аралашу күнекмәләрен үстерү;
- легендар шагыйрьләребезнең иҗаты аркылы балаларга эстетик һәм патриотик тәрбия бирү;
- туган илгә, туган якка, туган як табигатенә мәхәббәт тәрбияләү.

**Бәйгене үткәрүчеләр:**
«Мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба «Мәктәптән тыш эшләр үзәге»)

**Үткәрү формасы:** онлайн форматта, **видеоларны яки ссылкаларны** «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» почтасына салырга (ds-atn2@mail.ru ).

**Үткәрү срогы:** видеоларны 2026 нче елның 20 нче апреленә кадәр җибәреп бетерергә.

**Бәйгедә катнашучылар:** Әтнә районының балалар бакчасында тәрбияләнүчеләре, мәктәп укучылары һәм «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» укучылары.

**Бәйгедә катнашучы укучыларның чыгышлары 3 яшь категориясендә бәяләнә:**
1 нче категория: 5-6 яшьлек балалар;
2 нче категория: 7-9 яшьлек укучылар;
3 нче категория: 10-11 яшьлек укучылар.
Һәр балалар бакчасыннан һәм мәктәптән 2 укучы катнаша ала.

**Номинацияләр**:
- «Барыбызга уртак безнең газиз илебез» (Россиядә халыклар бердәмлеге елына багышлана);
- «Үзең үлсәң эшең калсын, мең яшәрлек имән булып» (Татарстан Республикасында хәрби батырлык һәм хезмәт фидакарьлеге елына багышлана).

**Бәяләү критерийлары:**
1. Укучының дөрес дикция белән сөйли белүе;
2. Интонация аша шигырьнең төп фикерен ача алуы;
3. Шигырьнең укучының яшь үзенчәлекләренә туры китереп сайлануы;
4. Укучының үз-үзен тотышы, сәхнә культурасы;
5. Чыгышның тәкъдим ителгән тематикага туры килүе.

**Катнашучыларның чыгышларына карата аерым таләпләр:**
- катнашучының чыгышы презентация, музыкаль бизәлеш белән баруы хуплана;
- чыгыш шигъри яки чәчмә әсәрдән алынган өзек булырга мөмкин.

**Бәйгене үткәрү һәм аңа йомгак ясау тәртибе:**
Бәйге нәтиҗәләре буенча җиңүчеләр һәр яшь категориясендә 1,2,3 урыннар өчен ***Диплом*** белән бүләкләнә. Калган катнашучыларга ***Катнашучы таныклыгы*** тапшырыла.